**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Чуваш Тимерлеге ав. **КАРАР**

«13 » октябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авыл җирлегендә гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 22 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 24 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Совет урамы, 58нче йорт адресы буенча кибет янында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылының Совет урамында 1-99, 1-10, 1-3нче йортларда, Лесная урамында, Совет тыкрыгында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 24 октябендә 14 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Центральная урамы, 3нче йорт адресы буенча мәктәп янында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк урамында 1-33, 1-14, 1-9нчы йортларда, Лесхоз, Нурлат урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Чуаш Тимерлеге авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, студентлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы сез?:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуваш Тимерлеге авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов